**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# «Каравон» рус халык бәйрәмен уздыру турында

2021 елда «Каравон» рус халык бәйрәмен уздыру максатларында һәм «Татарстан Республикасының бәйрәм көннәре һәм истәлекле даталары турында» 1992 елның 19 февралендәге 1448-XII номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясы нигезендә **карар бирәм:**

1. Җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы тәкъдимнәрен исәпкә алып, «Каравон» рус халык бәйрәмен 2021 елның 22 маенда Татарстан Республикасы Лаеш районының Никольское авылында, Татарстан Республикасы территориясендә яңа короновирус инфекциясе таралу куркынычы белән бәйле рәвештә кертелгән чикләү чараларын үтәп, уздырырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына «Каравон» рус халык бәйрәмен әзерләүгә һәм уздыруга ярдәм итәргә.

3. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына «Каравон» рус халык бәйрәмен әзерләүне һәм уздыруны массакүләм мәгълүмат чараларында яктыртуны оештырырга.

4. Җирле үзидарә органнарына, иҗтимагый берләшмәләргә һәм оешмаларга «Каравон» рус халык бәйрәмен әзерләүдә һәм уздыруда актив катнашырга тәкъдим итәргә.

5. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы
Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2021 ел, 28 апрель
№ ПУ-323